ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге законнарның үтәлеше турында

«Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге законнарның үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге законнарның үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Киләчәктә урман фонды җирләренә күчерү өчен авыл хуҗалыгы алып баруга яраксыз, шул исәптән агач-куак баскан, һәм урман үрчетүгә яраклы җир кишәрлекләре табу һәм аларны тикшерү эшен үткәрүне.

2.2. 2020 елның 7 октябрендәге 1614 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләренең территория һәм (яисә) урман чикләреннән кимендә 10 метр киңлектәге полосаны корыган үләннәрдән, урып-җыю калдыкларыннан, агач коры-сарысыннан, агач кисү калдыкларыннан, җитештерү һәм куллану калдыкларыннан һәм башка янучан материаллардан чистарту йә кимендә 1,4 метр киңлектә минераль катламга кадәр эшкәртелгән янгынга каршы полоса яисә янгынга каршы башка каршылык ярдәмендә аерып кую өлешендә үтәлешен тәэмин итү буенча урман янәшәсендәге территорияне (урман үсемлекләре белән капланган җирләрне) биләүче, файдаланучы һәм (яисә) аның белән эш итүче затлар белән эшне дәвам итүне.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Урманнардан файдаланучылар тарафыннан урман законнарын һәм урманнарны үзләштерү шартнамәләрендә, проектларында, шулай ук

урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларында каралган йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән эшне дәвам итүне.

3.2. Урман законнарын камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне өстәмә рәвештә законнар белән җайга салу зарурлыгы булганда, тиешле тәкъдимнәр әзерләүне һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертүне.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 3 июне
№ 76-VII ДСП